РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАМАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423643, РТ, Менделеевский район,
с.Камаево, ул. Дифгата Сирая д.29А

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАМАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423643 , РТ, Менделеевск районы,
Камай авылы, Дифгать Сирай урамы
29А йорты

Тел./ факс: 8(85549) 3-55-33, E-mail: Kam.Men@tatar.ru

---

Р Е Ш Е Н И Е | К А Р А Р

23 октябрь 2023 ел | №103

Менделеевск муниципаль районы
Камай авыл җирлеге Советының
2020 елның 27 февралендәге 149 номерлы
“Җир салымы турында»
карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлегенә ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге Советының 2020 елның 27 февралендәге 149 номерлы “Җир салымы турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. Карарның 2 пунктының 3 абзацында "һәм объектлар белән" сүзләрен “һәм (яисә) объектлар белән" сүзе белән алыштырырга, "объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуклы өлеш" сүзләрен "күчемсез милек объектына туры килә торган җир кишәрлеге өлешләре" сүзләре белән алыштырырга, "һәм объектларга” сүзләрен "һәм (яисә) объектларга" сүзләре белән алыштырырга;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында " Камай авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән алып бер ай узгач, әмма тиешле салым (иминият взнослары) буенча чираттагы салым (хисап) чорының 1 нче көненнән дә иртәрәк түгел, үз көченә керә.

Камай авыл җирлеге Советы рәисе | И.М. Ахунҗанов